Яңа Кармәт авыл җирлеге башкарма комитеты
Аксубай муниципаль районы
Татарстан Республикасы

Карар

№4 2021 елның 9 нче ноябре

“Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең Яңа Дума авыл җирлегендә халык җыены үткәрү турында”

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның № 131 - ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының “Яңа Кармәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2019 елның 5 ноябрендәге 98 номерлы карарына таянып.
Карар итте:
1. Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең Яңа Дума авылында Гагарин, Тукай, Кызыл Армия, Калинин урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 17ноябрендә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.
2. Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең Яңа Демкино авылында Киров, Карл Маркс урамнары буенча яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2021 елның 14 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.
3.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2022 елда Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге Яңа Дума авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә килешәсезме:
1)Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- кышкы чорда Яңа Дума авылы эчендәге юлларны карап тоту, Гагарин, Калинин, Тукай, Кызылармия, Карл Маркс, Киров урамнарын кардан чистарту буенча килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.
- Гагарин, Тукай, Кызылармия, Киров, Карл Маркс, Яңа Демкино урамнары буенча юллар салу өчен товарлар (грунт-вак һәм вак таш) сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр күрсәтү;

“ӘЙЕ” “ ЮК” “ТЫЕЛЫП КАЛДЫ"

4. Җыеннар үткәрү урыны-Татарстан Республикасы, Аксубай районы, Яңа Дума вылы, Калинина урамы 13а йорт адресы буенча яңа күләмле авыл мәдәният йорты .

5. Җыенны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплылыкны Яңа Кармәт авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

6. Әлеге карарны Яңа Кармәт авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://aksubaevo.tatar.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

7. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районының
Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы И. Р. Шакиров